**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**«Чирмешән авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге**
**гражданнары җыены**
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы
Чирмешән авыл җирлеге составына керүче Кече Чегодай торак пунктында

**01 ноябрь 2023 ел** **№ 8**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлеге составына керүче Кече Чегодай торак пунктында гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

1. 2024 елда Чирмешән авыл җирлегенең Кече Чегодай торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 сум күләмендә үзара салым кертергә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының, сугышчы-интернационалистларның тол хатыннарыннан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, «Өлкәннәр һәм инвалидлар өчен интернат-йорт» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесендә яшәүче гражданнардан, Луганск халык республикасында һәм Донецк халык республикасында махсус операциядә булган затлардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрергә:

- Чирмешән авыл җирлеге зиратларын төзекләндерү, реконструкцияләү, тоту, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- урам утларын, шул исәптән Чирмешән авыл җирлеге гомуми белем бирү учреждениеләре урам утларын монтажлау, кую, ремонтлау, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, кулланган электр энергиясе өчен чыгымнарны түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- Чирмешән авыл җирлеге торак пунктларында чишмә территорияләренең санитар-саклау зоналарын төзекләндерү һәм карап тоту, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар алу;
- иҗтимагый киңлекләрне төзекләндерү (урамнар буенча тротуарларны урнаштыру һәм капиталь ремонтлау, җир эшләре, брусчатка, бордюрлар урнаштыру), авыл җирлеге урамнарын карап тоту (үлән чабу, сабакларны, агачларны, төзелеш чүп-чарын җыештыру) триммерлар, ягулык-майлау

материаллары сатып алу, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- тракторны карап тоту, хезмәт күрсәтү, ягулык-майлау материалларын сатып алу, арба һәм махсус техника сатып алу, хезмәтләр өчен түләү, запас частьләр, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу чыгымнары.

3. Бу карарны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
ТР Чирмешән муниципаль районы
Чирмешән авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе М.Д.Шәйхетдинов